КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 28 декабрь г.Казань № 1304

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2020 ел, 25 декабрь, 1187 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2020 ел, 25 декабрь, 1187 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «22 533 728,0 мең сум» сүзләрен «16 932 348,5817 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «637 697,979 мең сум» сүзләрен «8 158 529,969 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «26 518,3 мең сум» сүзләрен «470 544,817 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «391 783,721 мең сум» сүзләрен «482 925,214 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «1 346 700,0 мең сум» сүзләрен «1 392 800,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип таныргa;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Транспорт системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә булышлык күрсәтү» ведомство максатчан программасы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә транспортны эксплуатацияләү күрсәткечләренә

карата норматив таләпләргә туры килә торган төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары озынлыгын арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән 6 004 974,3 мең сум күләмендәге программаны;

«Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидия исәбеннән юл эшләрен башкару чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән 7 583 294,272 мең сум күләмендәге программаны;

2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджеты акчасының калган өлеше исәбеннән 2021 елда финанслана торган, Татарстан Республикасы исеменнән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактлары өчен түләүгә каралган, әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2020 елда түләнергә тиешле 602 137,17795 мең сум күләмендәге юл эшләре күләмнәрен;

Татарстан Республикасының «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган «Түбән Кама шәһәре» монопрофильле муниципаль берәмлегендә инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә юнәлдерелгән 23 950,229 мең сум күләмендәге программаны.»;

2 пунктта «27 232 703,9 мең сум» сүзләрен «54 000 225,03125 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасын, «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты кысаларында Яр Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән программаны яңа редакциядә (kararга теркәләләр) бәян итәргә;

«2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә керү юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән программаны төшереп калдырырга;

әлеге карарга «Транспорт системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә булышлык күрсәтү» ведомство максатчан программасы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә транспортны эксплуатацияләү күрсәткечләренә карата норматив таләпләргә туры килә торган төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары озынлыгын арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән программаны, «Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидия исәбеннән юл эшләрен башкару чараларын

тормышка ашыруга юнәлдерелгән программаны, 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджеты акчасының калган өлеше исәбеннән 2021 елда финанслана торган, Татарстан Республикасы исеменнән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактлары өчен түләүгә каралган, әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2020 елда түләнергә тиешле юл эшләре күләмнәрен, Татарстан Республикасының «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган «Түбән Кама шәһәре» монопрофильле муниципаль берәмлегендә инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә юнәлдерелгән программаны (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин